РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » 12 2023 г. №2096

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы «Күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле дәрәҗәдә сыйфатлы түгел итеп һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып киткән тоткарлыклар белән идарә итү, тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм башкару очрагында торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 491 номерлы карары, Россия Төзелеш Министрлыгының 06.04.2018 № 213/пр «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урынын тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау турында, торак урынын тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча карар турында» боерыгы белән, Татарстан Республикасының 28.07.2004 № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга минималь взнос күләмен билгеләү турында” 29.06.2013 № 450 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 03.12.2019 № 1097 Карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне билгеләргә:

- 1 нче номерлы кушымта нигезендә, социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен 2024 елга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләүне).

- 2024 елга социаль наем шартнамәләре, муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау

өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы торак йортта торак урыннары милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 декабрендәге 1081 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/адресы буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

Габдрахманова Г.Г.
2-42-06

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
__________ 2023 ел № _____
Карарына 1 нче кушымта

**2024 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) түләү күләме**

| Түләүнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2024 елның 1 гыйнварыннан түләү күләме | 2024 елның 1 июленнән түләү күләме |
|---|---|---|---|
| Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урынны наемга алган өчен түләү | сум/кв.м. | 7,58 | 8,11 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________ 2023 г. № ____
Карарына 2 нче кушымта

**2024 елга социаль наем шартнамәләре, муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы торак йортта торак урыннары милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме**

| **Хезмәтнең исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **2024 елга тариф 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июленә кадәр** | **2024 елга тариф (01.07.2024 елдан 31.12.2024 елга кадәр)** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Торак фонды белән идарә итү | сум/м2 | 1,69 | 1,81 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | сум/м2 | 2,03 | 2,17 |
| Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | сум/м2 | 3,89 | 4,16 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту: | сум/м2 | | |
| суүткәргеч-канализация челтәрләре | | 2,49 | 2,66 |
| газ белән тәэмин итүнең фасад һәм йорт челтәрләре | | 0,38 | 0,41 |
| электр белән тәэмин итү челтәрләре | | 1,40 | 1,50 |
| Капиталь ремонт | сум/м2 | 6,48 | 6,93 |